■ КПСС райкомы пленумына

# Хакыйкать ачы булса да

Миңа эшләгән дәвердә партия поручениеләрен күп үтәргә туры килде. Вакытлыча партия оешмасы секретаре вазифасын башкарган чакларым да шактый булды. Моны бары бер нәрсә—партоешма һәм аның бюросы эшчәнлеге белән таныш булуымны белдерү өчен генә әйтәм.

Ул чакларда партбюро хезмәт коллективында аңлату эшләре алып бару, дисциплинаны ныгыту, яшьләрне тәрбияләү һәм башка мәсьәләләргә дә зур игътибар бирә торган иде. Бүгенге күппартиялелек заманасында партоешманың бурычлары һәм эше тагын да катлаулана. Хәзер һәр коллективта хәл ителмәгән проблемалар бик күп. Мондый шартларда коллектив әгъзалары коммунистларга күз сала: алар үзләрен ничек тоталар. Шуны искә алырга һәм һәр КПСС әгъзасына әхлак нормалары ягыннан үрнәк булырлык эш итәргә кирәк.

Халык белән эшләгәндә тагын бер нәрсәгә әһәмият бирү зарури. Илебездә катлаулы заманда халык белән ачыктан-ачык сөйләшү, аңа хакыйкатьне аңлату кирәк. Хак сүз авыр, ачы булса да, халык үзе бик белеп әйткәнчә, төче ялганнан татлырак. Һәм бүген партия турында сөйләшүдән читләшергә дә ярамый, бу аппонентлар алдында артка чигүгә тиң. Партиядәге бүгенге проблемалар, аларның сәбәбе, шушы хәлдән чыгу юллары, үзгәртеп коруның партия оешмаларында ничек баруы турында объектив сөйләшү, аңлашу кирәк. Бары шул вакытта гына партия оешмасына, аның секретарена хезмәт кешеләре ышаныч белән карарлар. Абруйны бары шушы юл белән генә кайтарырга мөмкин.

**И. ЕРЕПОВ,**
Сугыш һәм хезмәт ветераны. КПСС члены.

*● Бөек Ватан сугышы башлануның 50 еллыгына карата*

# 333 нче номерлы тоткын

**Аның исеме, фамилиясе дә юк иде, бары номеры—ул 333 нче номерлы гына иде.**

Курск-Белгород юнәлешендә зур көчләр туплап немец командованиесе бу шәһәрләрне алырга һәм кабат Мәскәүгә юл ачарга исәп тотты.

Бу юнәлештә канкойгыч сугышлар башланып китте. Безнең гаскәрләр кискен каршылык күрсәтте. Калкулыкларның берсендә Себердән килгән полк частьләре оборона тотты. Полкның сул флангысында автоматчылар, уң якта ПТР (танкка каршы ата торган мылтык) ротасы урнашкан. Соңгысында взвод командиры ярдәмчесе сыйфатында Иван Бородин сугышты.

Көчләр тигез түгел иде. Фашист частьләренең басымы астында автоматчылар чигенде һәм ПТР ротасы камалышта калды. Солдатлар батырларча сугыштылар. Алар арасында үлүчеләр, яралылар арта барды. Снаряд кыйпылчыкларының берсе Бородинның тезенә килеп эләкте.

Бу аның өченче кабат яралануы иде инде. Беренче тапкыр иңбашына пуля Клин шәһәре районында сугышларда тиде, икенче тапкыр авыр яраланды, осколок яңагын тишеп авыз эчен каты җәрәхәтләде. Анысы Калинин шәһәре өчен барган сугышларда булды.

..Дошман боҗрасы кысыла барды. Сугышчан расчетлар тынып кала тордылар, сугыш кирәк-яраклары бетте. Берничә исән калган яралы сугышчыны шунда немецлар әсирлеккә алдылар.

Газап күреп яшәүләр шуннан башланды. Берничә көн санчастьтә тоткannan соң аларның барысын, товар вагонына тутырдылар да, Германиягә алып киттеләр. Станцияләрнең берсендә ыгы-зыгы, этләр өрүе һәм конвой кычкыруы астында аларны вагоннардан бушаттылар, тезделәр һәм алып киттеләр. Юл михнәтеннән җәфаланган әсирләр өчен бу юл тәмугка бару кебек кыен иде. Чак кына артка калсаң аркаңа мылтык түтәсе белән бәрәләр. Шул чагында аягында басып кала алмасаң, егылсаң—атып калдыралар. Бу юлда мәетләр аз калмады. Алар арасыннан физик яктан иң ныклары гына билгеләнгән ноктага барып җитә алды.

Лагерь, соңыннан билгеле булганча, Герлиц шәһәренә урнашкан иде. Аларны баракларга куып керттеләр. Лагерь чәнечкеле тимерчыбык белән уратылып алынган, вышкада пулеметлар куелган сакчылар тора. Иртән һәм кичен аларны ишек алдындагы мәйданга тезәләр, номерлар буенча барлыйлар. Аңа 333 нче номер эләгә. Барлау вакытында шул номерны әйтергә чак кына соңгарсаң яңагына сугып җибәрәләр, сафта селкенсәң икенче удар аласың. Лагерьда көнгә 150 грамм пычкы чүбе катнаштырылган эрзац-ипи һәм бер тәлинкә шулпа дип исемләнгән сыеклык бирәләр. Кешеләр ачлыктан дистәләрчә үлә. Лагерьда бөтен эш кабер казу һәм үлгәннәрне күмүгә кайтып кала.

Көн саен лагерьга «сатып алучылар» килә. Алар хезмәткә яраклыларны сайлыйлар, номерлары буенча чакыралар. Шулай 333 номерлы әсир шахтага эшкә эләгә. Аңа, кызылармеец формасы күптән тузып төшкән булганга, эш киеме, аягына агач башмаклар бирәләр. Иртән бу тоткыннарны конвой шахтага алып китә. Анда да хәл җиңелдән түгел, чак кына күрсәткәннән читкә тайпылдыңмы, яисә акрынрак эшләгәнеңне күрделәрме—сугып егалар. Торып басуга икенче удар аласың. Төшкегә гәрәнкә баландасы, кичен бәрәңге кабыклары катнаштырылган аш, бер телем ипи бирәләр. Ипи көнлек норма: теләсәң шунда ук ашыйсың, кирәк тапсаң өчкә бүләсең. Шахтада эш авыр, кич кайтканда әсирләр аякларын көчкә сөйриләр.

Бородин бер иптәше белән качарга карар кыла. Эш киемен әсирләр баракка кайткач үз номерлары язылган элгечтә калдырырга тиеш булалар. Качарга ниятләгәч, аларны үзләре белән алалар, мендәр астына яшерәләр. Төнлә ачык тәрәзә аркылы чыгарга исәп тоткан булалар. Киемэлгечнең тикшерелүен алар белмиләр, әлбәттә.

Аларның качарга җыенуын шулай беләләр, каты кыйныйлар һәм җиде тәүлеккә карцерга ябалар. Анысы караңгы таш капчык, көнгә 150 грамм эрзац-ипи һәм бер стакан су бирәләр. Әмма яшь организм барыбер бирешми.

—Төгәл әйтә алмыйм,—ди Бородин,—әмма миңа лагерьда яшерен оешма хәрәкәт итә шикелле тоела иде. **Санинструктор** булып эшләүче рус әсире хәлсезләнгәннәрне авыру сылтавы астында госпитальгә җибәрергә җай таба иде. Аның аркылы ук безнең гаскәрләрнең уңышлы һөҗүм хәрәкәтләре турында хәбәрләр ала тордык.

Бервакыт лагерьга власовчылар еш килә башлый. Алар үз армияләренә чакыралар, тук тормыш вәгъдә итәләр, әмма әсирләрдән берәү дә бу командага язылмый.

Җиңү якынлашып килгәнне әсирләр сакчыларның тәртибенә карап сизәләр. Янәшәдә эшләүче немец шахтерлары да әсирләргә мәрхәмәтлерәк карый.

1945 елның 8 маенда иртән беркем дә әсирләрне эшкә кумый. Баракләрдан чыксалар, сакчыларның эзе дә калмаган, кая киткәннәрен дә белүче юк. Ә берничә сәгатьтән безнең сугышчылар лагерьга килеп керә. Ул чактагы шатлыкны тасвирлап бирүе бик кыен: кочаклашулар, үбешүләр китә. Бородин да—333 нче номерлы тоткын үзенең чын исемен ала, Иван Алексеевич Бородинга әверелә. Әсирләрне җыялар һәм махсус пунктка барырга күрсәтмә бирәләр. Тоткыннар сөенешеп шунда китәләр. Җентекләп тикшергәннән соң Бородинны хәрәкәттәге армиягә җибәрәләр. Аннан ул ноябрь аенда демобилизацияләнә.

Туган ягына кайткач, **Иван Алексеевич** беркадәр өйдә дәвалана, аннан элеваторда киптерү буенча мастер булып эшли. Йөзендә калган кыйпылчыкларны алу өчен кабат операция ясала. Ул сәламәтлеге буенча инвалидлыкка чыга.

Тоткынлыкта күргән газаплары, җәрәхәтләре һәм авырулары аны даими эзәрлекли. 333 нче номерлы тоткын безнең совет кешесе, сугышчан юл үткән солдат Иван Алексеевич Бородин **вакытыннан элек** үлә. Әмма кешеләр күңелендә ул һаман да саклана.

**И. САНДЛЕР.**

# Кайгыртучанлык булса, эш тә бара

**Краснодар крае.** Яңа Кубань районының «Родина» колхозы күптармаклы бай хуҗалык. Аның 15 мең гектар сөрү җире, 5 товарлыклы-сөтчелек, 4 сарыкчылык фермасы, мөгезле эре терлек үстерү, дуңгыз симертү фермалары бар. Болар барысы да колхозга 1973 елдан башлап дәүләт кредитыннан файдаланмыйча яшәргә мөмкинлек бирә.

Җитәкчеләр һәм белгечләр хезмәтенә түләү хуҗалык исәпле заданиеләрне үтәү нәтиҗәләренә бәйле куелган.

Хуҗалыкка 20 елдан артык инде Социалистик Хезмәт Герое Павел Яковлевич Штанько җитәкчелек итә.

—Хәзер шушындый чор: хезмәт кешесенең производстводагы эш нәтиҗәсе хезмәт һәм көнкүреш шартларына нык бәйле,—ди председатель. Менә ни өчен социаль сферага (ә хуҗалык счетында 40 миллионнан артык акча бар) миллионнарны бүләбез. Авылларга газ килә, 600 урынлы залы булган культура йорты, яңа мәктәп, көнкүреш йорты, балалар бакчасы төзелде. Колхоз торак йортлар да төзи, колхозчылар үзләре дә йортлар салалар. Югары уку йортларына колхоз стипендиатлары укый.

Шулай да авыл кешеләренең проблемалары җитәрлек. Авыл Советы председателе Л. Н. Орлова янына көн саен берничә кеше килә.

—Бездә әле конкрет кеше турында конкрет сөйләшү җитеп бетми,— ди Людмила Николаевна.







**Рәсемнәрдә» «Родина» колхозындагы яңа культура йорты;**

**ипи пешерүчеләр Светлана Проценко һәм Валентина Хатанзеева;**

**колхоз мастерскоенда шәхси машиналарны ремонтлау буенча участок ачтылар. Запас частьләрне үзәкләштерелгән юл белән алалар, ә үзең өчен ремонтны начар үткәрү—отышсыз.**

**ТАСС фотохроникасы.**

## *Татарстан яңалыклар агентлыгы*

### «ГАРАНТ» ҖИНАЯТЬЧЕЛӘРНЕ ТОТА

ЯР ЧАЛЛЫ. Тукай районы РОВДсында бакчачылык җәмгыятьләрен саклау өчен ведомстводан тыш саклык булдырылган. Җинаятьчеләр белән көрәшү күнегүе булган физик яктан нык граждannар аның әгъзасы була алалар. Алар махсус кием кигәннәр, рация белән йөриләр. Аларга милиция работниклары һәм янгын сүндерү сакчылары ярдәм итә. Подразделение отряды бакчачылар, җәмгыятьләр белән килешү төзи һәм аларны үз яклауларына алалар.

Нәтиҗәләре: «Гарант» хәрәкәт итә торган зонада бакча өйләрен талау кискен кимеде, быел гына да уннарча кеше тотылды.

### ТЕШЛӘРНЕ НЫГЫТУНЫҢ ЯҢА МЕТОДЫ

ПИТРӘЧ. Үзәк район больницасында тешкә куела торган металл тышлыкларны (протезларны) титан нитриды белән каплау кабинеты ачылды. Ул төрле пробадагы алтынны имитацияли. Аны ион-плазма методы белән булдыралар. Яңа металл агрессив тирәлектәге тәэсиргә чыдам (кислота, селтегә), коронкаларга бик матур тышкы күренеш бирә, тырналган урыннарны каплый, металл тәмен бетерә.

# Йөзгә кызыллык китермәдем

Республика телевидениесенә баргач, миңа үз эшем турында сөйләргә кушты-лар. Дөресен генә әйтергә кирәк, мин бу тәкъдимне кире кактым. Икенче бер терлекче аның каравы «теттереп» мактанды. Авылдагылар аңардан ачыктан-ачык көлделәр. Бездә шундый караш бит, үз эше турында сөйли башлый икән, нигәдер андыйларны өнәп бетермиләр, синең турыңда икенче берәүләр сөйләргә тиеш сыман... Ләкин үз эше турында берәү дә анда эшләүченең үзеннән яхшы белми инде.

Фермага 1953 нче елда килдем. Бетенләй бала идем әле. Ул вакытта бит хәзерге шикелле группаларда сыерлар күп түгел, нибары уникәү генә булды. Барлык эшләрне, әлбәттә, кулдан башкардык, кул белән саудык та. Мин килгәндә дә, аннан соң да Нәсимә, Минҗамал, Асия апалар шактый вакыт сыер савучылар булып эшләделәр. Аларны беренче остазларым дип тә әйтәм. Күп нәрсәгә, шул исәптән тәҗрибәгә дә алар аша өйрәндем.

217 баш терлеккә печәнне үзебез күтәреп кертеп сала идек. Кукурузны да үзебез чалгы белән чаптык, аннан атлар белән фермага кайтардык. Көненә 8 әр машина жом бушатуыбызны күз алдына китерсәм, хәзер дә тәннәрем чемердәп куя. Ә капчыкларга без төягән оннарны исәпкә алсаң, кызык, күпме булыр иде икән? Хәзер генә ул барысы да башкача. 3052 баш терлеккә онны берүзем төйим, билгеле, кнопкага басып кына.

1965 елларда җәйге чорда чөгендергә дә чыктым. Бу елны татлы тамырның гектарыннан безнең «Дружба» колхозы 317 центнер уңыш алды. 1970 нче елларда да чөгендер сирәкләү эшләрендә катнаштым. Шуның өчен хуҗалык миңа 13 капчык шикәр комы бирде һәм «Аеруча хезмәт күрсәткәне өчен» медале белән бүләкләде.

1970—75 елларда тудыру бүлегендә бозаулар карадым. Хезмәт биредә дә җиңел түгел иде, йөзгә кызыллык китермәс өчен барысы белән килешеп эшләдем, авырлыкларга да түзәргә туры килде. Мөнҗия Мөхәммәтҗанова белән алты айга кадәр бозаулар карадык, алардан 925әр грамм тәүлеклек артым алуга ирештек.

Аннан, мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмә оешкач, биредә хезмәт куя башладым. Бу вакытта Мәлия Зөлкәрнәева, Нурия Идиятуллина, Салих Кадыйровлар белән бергә эшләдек. Әйтергә кирәк, Салих белән без бер класста укыдык, фермага да бергә килдек. Баштагы елларны ул атлар карады, хәзер берләшмәдә терлекләр симертә. Үз эшенә Салих зур җаваплылык хисе белән карый, шул ук вакытта сабыр холыклы, кушканны җиренә җиткереп үти дә.

Терлекче Солтан Хәсәновны да шундый ук тырыш кеше дияр идем. Авыр чакларда гел булышырга, ярдәм итәргә әзер тора. Безнең коллектив бердәм, дус-тату булганга, берәү дә китек күңел белән эшләми. Бер-беребезне аңларга, үз-үзебезгә карата игътибарлырак булырга тырышабыз.

1975 еллардагы хезмәтемне олылап хөрмәтләделәр, рәхмәт. «Социалистик ярышта җиңүче», «Тугызынчы бишьеллык ударнигы» исемнәре бирделәр.

Эштә генә чын бәхетне табып була. Мин моңа эшли-эшли инандым. «Иң әйбәт терлекче» исеменә исә 1980 елда лаек булдым. 1980—1985 еллар—хезмәтемнең чәчәк аткан чоры. Яхшы күрсәткечләргә ирешкәнем өчен Татарстан АССР халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең «Мактау грамотасын» алдым. Терлекләрне уңышлы кышлаткан, җитештерүчәнлекне арттырган һәм терлекләрдән кышкы чорда яхшы продукция алган өчен 1985 елның I кварталында республика терлекчеләре арасында үткәрелгән ярышта җиңеп чыктым. 280 баш мөгезле эре терлектән 1000 грамм уртача тәүлеклек үсеш алырга социалистик йөкләмә кабул итсәм, аны 1331 граммга җиткердем. Шул ук елны октябрь аенда Татарстан өлкә комитеты, Министрлар Советы, профсоюзларның өлкә комитеты һәм ВЛКСМ өлкә комитетының чакыруы буенча Казан шәһәрендә республика агропромышленность комплексы работниклары активы җыелышында мин дә катнаштым.



Алда әйтеп үткән уңышларда иремнең апасы Миңнеруйның да ярдәме зур булды. Аның белән 33 ел бергә гомер кичерәбез. II группа инвалид үзе. Ул мин кайткан төшкә ашын пешереп, йорт-җирне карап торды, хәзер дә хәленнән килгәнчә эшләшеп йөри. Каенанам да бик игелекле булды. 23 ел яшәү дәверендә аның авыр сүз әйтүен хәтерләмим. Балаларым да кешелекле булып үстеләр, калган көннәрдә рәхәт гомер кичерсеннәр инде. Галиям Яңа Иглайга килен булып төште, ире Госман тракторчы. Өч бала үстерәләр. Наилә Зирекле авылында укыта, ире Тәлгать колхозның иң мактаулы комбайнчыларыннан санала. Бер малай һәм бер кызлары бар. Гүзәлиям Казанда милиция сержанты булып эшли. Ире Рафик та милиционер. Мин исә бүгенге көндә дә мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмәдә хезмәт куям. Лаеклы ялга чыгарга аз гына вакыт калып бара инде. Безнең сафларга таза-сау, эш сөючән яшьләрнең килүен көтәбез.

**Мәрбия ТУКТАМЫШЕВА,**
терлекче.



# Бердәм коллектив

**Юлия Германовна Саврандейкина исеме районда күпләргә мәгълүм инде. Ул «Россия» колхозының товарлыклы-дуңгызчылык фермасына 5 ел инде җитәкчелек итә. Анда кадәр ул товарлыклы-сөтчелек фермасында веттехник булып эшләде.**

**Юлия Германовна килгәч дуңгызчылык фермасында эш сизелерлек яхшырды,хезмәт күрсәткечләре көннән-көн күтәрелә барды.**

**Юлия Ивановна Имукова дуңгызчылыкта ун елдан артык хезмәт куя инде. Аңа каплатудагы ана дуңгызлар беркетелгән. Ул маллардан сәламәт, тормышчан үрчем ала. Алган үрчемне имүдән аерганчы үзе карый. Ә аннан соң дуңгыз балаларын үстерү группасына тапшыра.**

**Юлия Германовна җитәкләгән коллектив тырышлыгы белән колхоз дәүләткә ит сату заданиесен елның елында арттырып үтәп килә.**

**Рәсемдә: Юлия Германовна Саврандейкина (уңда) һәм Юлия Ивановна Имукова.**

**Безнең фотохәбәрчебез Н. Азизов аларны узган ел районның алдынгы терлекчеләре слетына килгәч рәсемгә төшереп алган булган.**

# Сөт фронтында

«Комбайн» колхозының җәйге лагере авылдан ерак түгел җирдә урнашкан. Аның бер ягында урман, янәшәсендә генә «Гәрәй» елгасы җәйрәп ята. Сыер савучы хатын-кызлар биреләгә ашкынып киләләр. Ни әйтсәң дә, җәйге чор үзе бер рәхәтлек ич.

Хуҗалыкта барлыгы 320 савым сыеры исәпләнә, шулар арасында егерме сигезе беренче кат бозаулаганнар.

Сыер савучылар Фидания Корбанова, Зәйтүнә Гайсина, Сания Гайнетдинова үз карамакларындагы һәр сырдан тәүлегенә уртача 13әр килограмм сөт савалар. Әкълимә Исхакова бу савучылардан азга гына калыша (аның әле сыерлары бозаулап бетмәгән). Билгеле, җәйге чорда бу күрсәткечләр белән генә канәгатьләнеп калу мөмкин түгел, шуңа да сыйфатлы продукция алуны арттыруда булдыра алганча өлеш кертү—һәркемнең изге бурычы.

Нәсел алу эшенә дә товарлыклы-сөтчелек фермасында зур игътибар бирелә. Сыерлар Латвиядән кайтарылган үгезләр белән каплатылалар.

Әйтергә кирәк, җәйге лагерьда су белән өзеклекләр килеп чыкканы юк. Оператор Әсгать Сәхипгәрәев тырышлыгы аркасында савучылар җылы суга мохтаҗлык кичермиләр.

Көтүчеләр Рәис Нуриев, Фәрит Гарифуллин, Гомәр Мөхсинов, Надыйр Мәхмүтов, Наил Әюпов, Рәис Гатин да үз эшләренә зур җаваплылык хисе белән карыйлар, алар сыерларны төшкә хәтле урманда, ә төштән соң әрәмәлектәге болында көтәләр.

Малларны яхшы сыйфатлы терлек азыгы белән тәэмин итүдә тракторчы Әмин Шәрәповның да зур өлеше бар. Ул көненә яшел масса төяп 3—4әр рейс ясый, кичке савымга фуражын да китерә.

Әнә шул рәвешчә комбайнлылар сөт фронтында бары уртак тырышлык нигезендә генә мул продукция алып булуын яхшы аңлыйлар, шуңа да оешкан төстә, бердәм эшләргә тырышалар.

**С. ФӘТХЕТДИНОВА,**
«Комбайн» колхозы.

# *Сенаж салалар*

**Хафизов исемендәге колхозда печән әзерләү белән бергә сенаж салуга да зур әһәмият бирелә. Хәзерге көнгә 795 тонна сенаж салынды инде. Үләннәрне чабуда Федор Мурзин, Андрей Сибулатов, Валерий Таймуллин кебек алдынгы механизаторлар сенаж салу конвейерына тон бирәп эшлиләр.**

**КСК-100 комбайнында һәм КПКУ-1 агрегатында үләнне тапатып төяүче Рифкать Вәлиуллин, Александр Илеверов та эш темпларын югары саклыйлар.**

**Яшел массаны базларга ташып торучы шоферларга да аларны тоткарламас өчен зур өлгерлек күрсәтеп, эш сәгатьләре белән санашмыйча эшләргә кала. Петр Сидоров, Геннадий Кузьмин, Әхәт Шәйдуллин кебек уңганнар вакытның мөһимлеген аңлап, шулай итәләр дә. Аларның көнлек нормалары 120 процентка үтәлә.**

# Эштә аларга тиңнәр юк

«1 май» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасы хезмәтчәннәре кабул итеп алган йөкләмәләрне һәм еллык планнарны уңышлы үтәү өчен зур тырышлык куеп, икеләтә энергия белән эшлиләр.

Агымдагы елның алты аенда Нина Михайловна Варламова белән Елена Ивановна Гаврилова профилакторий группасындагы 1 айга кадәр булган бозаулардан 600 әр грамм уртача тәүлеклек үсеш алуга ирештеләр. Ә бер айдан алып дүрт айга кадәрге мөгезле эре терлекләрдән Надежда Алексеевна Семенова, Людмила Васильевна Захарсва 800 әр грамм уртача тәүлеклек артым алдылар.

Хуҗалыкның сыер савучылары да яхшы һәм сыйфатлы продукт алу өчен булган мөмкинлекләрдән файдаланып эшләргә тырышалар.

Мәсәлән, шул фермада өч дистә елдан артык хезмәт куючы Елена Максимовна Короткина былелгы елның алты аенда 1464 килограмм сөт саудды.

Бер кат бозаулаган сыерларны савучы Мария Маськина, Татьяна Щеголкованың савымы да һәр сыерга 1328 килограмм.

Маллар даими рәвештә яшел азык белән тәэмин ителәләр. Аларга азыкны МТЗ-80 тракторында Александр Васильевич Семенов һәм Петр Петрович Назаров китереп торалар, үзләре чабалар да.

**Н. ГРИГОРЬЕВ,**
экономист.

